ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 20 » июль 2018 ел № 120

Балтач муниципаль районы бюджет учреждениеләре территорияләрен төзекләндерү буенча смотр-конкурс үткәрү турында

Балтач муниципаль районы бюджет учреждениеләре территорияләрен карап тотуны, төзекләндерүне яхшырту, киң даирә җәмәгатьчелекне һәм район халкын Балтач шәһәр тибындагы поселогын һәм муниципаль район торак пунктларын төзекләндерү һәм яшелләндерү эшләренә җәлеп итү максатыннан, Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. 2018 елның 16 июленнән 2018 елның 31 августына кадәр Балтач муниципаль районы бюджет учреждениеләре территорияләрен төзекләндерү буенча смотр-конкурс игълан итәргә.

2. Балтач муниципаль районы бюджет учреждениеләре территорияләрен төзекләндерү буенча смотр-конкурс турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

3. Балтач муниципаль районы бюджет учреждениеләре территорияләрен төзекләндерү буенча смотр-конкурс үткәрү комиссиясе составын расларга (2 нче кушымта).

4. Балтач муниципаль районының бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә смотр-конкурста катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына җиңүчеләрне бүләкләү өчен Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты һәм Балтач шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты бюджетларыннан акча бүлеп бирүне күздә тотарга.

6. «Татмедиа» ААҖ филиалы «Хезмәт»кә район газетасы битләрендә смотр-конкурс үткәрүнең барышын даими яктыртуны тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башлыгы урынбасары Н. Н. Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль районы
башлыгы Р.Р. Нотфуллин